Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгы

«11» март 2022
№ под-412/22/642

БОЕРЫК

Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмасында тәрбияләнүче зат белән бергә булуны оештырганда дәвалау оешмасы, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмасы һәм дәүләтнеке булмаган коммерциясез, шул исәптән иҗтимагый һәм дини оешма, хәйрия фонды яисә ирекле ярдәмче (волонтер) арасында үзара хезмәттәшлек турында шартнамә рәвешен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Стационар шартларда аларга дәвалау ярдәме күрсәтелгәндә дәвалау оешмасында ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмалары хезмәткәрләренең, шулай ук дәүләтнеке булмаган коммерциясез оешмалар, хәйрия фондлары вәкилләренең һәм ирекле ярдәмчеләрнең (волонтерларның) ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар белән бергә булуны оештыру тәртибен раслау турында» 2021 елның 8 декабрендәге 1200 номерлы карары нигезендә боерык бирәбез:

1. Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмасында тәрбияләнүче зат белән бергә булуны оештырганда дәвалау оешмасы, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмасы һәм дәүләтнеке булмаган коммерциясез, шул исәптән иҗтимагый һәм дини оешма, хәйрия фонды яисә ирекле ярдәмче (волонтер) арасында үзара хезмәттәшлек турында шартнамәнең кушымтада бирелә торган рәвешен расларга.
2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлегенә (В.О.Васильева) боерыкны кабул иткәннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.
3. Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
мәгариф һәм фән министры
_______________И.Г. Һадиуллин

Татарстан Республикасы
сәламәтлек саклау министры
__________________М.Н.Садыйков

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән
министрлыгының 11.03.2022
№под-412/22 боерыгы белән
расланды.

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгының 11.03.2022
№642 боерыгы белән расланды.

Үрнәк

Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмасында тәрбияләнүче зат белән бергә булуны оештырганда дәвалау оешмасы, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмасы һәм дәүләтнеке булмаган коммерциясез, шул исәптән иҗтимагый һәм дини оешма, хәйрия фонды яисә ирекле ярдәмче (волонтер) арасында үзара хезмәттәшлек турында шартнамә

«____» ___________ 20__ ел. № ____

____________________________________________________________________________________,
(ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешма исеме)
киләчәктә «Учреждение» дип атала, директоры
____________________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
эш итү нигезе___________________________________________________________
(вазыйфаи затка эшчәнлеген гамәлгә ашыруга нигез булган документ, шул исәптән хокукый акт)
____________________________________________________________________________________,
____________________________________________________________________________________
(дәвалау оешмасы исеме)
киләчәктә «Дәвалау оешмасы» дип атала, директоры
____________________________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
эш итү нигезе_____________________________________________________________
(вазыйфаи затка эшчәнлеген гамәлгә ашыруга нигез булган документ, шул исәптән хокукый акт)
____________________________________________________________________________________,

һәм________________________________________________________________________________
(ирекле ярдәмченең (волонтерның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) яки коммерциясез оешма атамасы, җитәкчесе (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
эш итү нигезе _____________________________________________________________
(паспорт белешмәләре яисә вазыйфаи затка эшчәнлеген гамәлгә ашыруга нигез булган документ, шул исәптән хокукый акт)
алга таба «Озата йөрүче», бергә «Яклар» дип атала, түбәндәгеләр турында Шартнамә төзеделәр.

**I. Шартнамә предметы**

1.1. Бу Шартнамәдә стационар шартларда дәвалау ярдәме күрсәтелгәндә Дәвалау оешмасында бергә булуның расланган графигы нигезендә Озата йөрүченең ятим бала һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган бала (алга таба – тәрбияләнүче) белән бергә булуын оештыру тәртибен билгели.

Озата йөрүче, стационар шартларда аңа дәвалау ярдәме күрсәтелгәндә, 202__ елның «___»__________ башлап Учреждениенең әлеге тәрбияләнүчесен Дәвалау оешмасында озата йөрүгә кабул итә: _________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), туу датасы, туу турында таныклык (паспорт) №,
_____________________________________________________________________________.

сериясе, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

Дәвалау оешмасы бергә булу графигын дәвалау процедураларын үткәрү вакытын исәпкә алып раслый.

1.2. Әлеге Шартнамә нигезендә Озата йөрүче түбәндәгеләрне гамәлгә ашыру йөкләмәсен үз өстенә ала (тәрбияләнүченең ихтыяры буенча һәм Дәвалау оешмасы белән килешү буенча):

ял чараларын оештыру (бүлмә эчендә һәм саф һавада уеннар; иҗади дәресләр, очрашулар уздыру; театральләштерелгән тамашалар кую; бәйрәмнәр оештыру һәм үткәрү; изотерапия сеанслары үткәрү; музыкаль терапия сеанслары үткәрү; видео- һәм кинофильмнар күрсәтү; тәрбияләнүче белән берлектә хастаханә газеталары һәм журналлары чыгару; кычкырып китап уку, тәрбияләнүчеләрнең ялын оештыруның башка төрләре һәм күңел ачу чаралары);

укыту чараларын оештыру (лекцияләр үткәрү; компьютер белеме буенча дәресләр үткәрү; гомуми белем бирү программасын, урта һөнәри белем бирү программасын үзләштерүдә ярдәм итү; өстәмә белем алуда ярдәм итү; белем бирү эшчәнлегенең башка төрләре);

авыр тормыш шартларында тәрбияләнүче белән аралашу һәм әхлакый ярдәм күрсәтү;

тәрбияләнүче белән иҗади дәресләр үткәрү;

тәрбияләнүчегә көнкүреш ярдәме күрсәтү (ризык ашауда ярдәм итү, киендерү, дәвалау процедураларына озата бару, санитар-гигиена хезмәте күрсәтү).

## II. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Озата йөрүче зат түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

учреждениенең җитәкчелеге белән килештермичә тәрбияләнүчене Дәвалау оешмасыннан читкә алып чыгарга;

тәрбияләнүчене Россия Федерациясе территориясеннән читкә чыгарырга;

социаль челтәрләрдә, ММЧда тәрбияләнүче һәм Учреждение эшчәнлеге белән бәйле фото- һәм видеоматериаллар бастырып чыгарырга;

тәрбияләнүчене өченче затлар күзәтүе астында калдырырга.

2.2. Озата йөрүче Дәвалау оешмасында булу кагыйдәләрен үтәргә тиеш.

2.3. Учреждение стационар шартларда аңа дәвалау ярдәме күрсәтелгәндә тәрбияләнүчене Дәвалау оешмасында озата йөрү шартларын контрольдә тотарга хокуклы.

2.4. Учреждение бурычлы:

тәрбияләнүченең законлы вәкиле вазыйфаларын, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Дәвалау оешмасында вакытлыча тору чорында аның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауны гамәлгә ашырырга;

тәрбияләнүченең тормыш шартларын тикшерүдә тотарга, атап әйткәндә: тәрбияләнүченең сәламәтлек торышын, психологик торышын һәм гигиенасын бәяләргә;

әлеге Шартнамәне өзгән очракта бер тәүлек эчендә Озата йөрүчене алмаштырырга.

2.5. Дәвалау оешмасы хокуклы:

Озата йөрүченең һәм тәрбияләнүченең дәвалау планы нигезендә бергә булу графигын билгеләргә;

тәрбияләнүченең сәламәтлеге начарайган очракта яки дәвалау планы нигезендә дәвалау процедураларын үткәрү зарурилыгы билгеләнгән очракта ял, иҗади һәм башка чараларны үткәрүне туктату таләп итәргә;

Озата йөрүче, тәрбияләнүче тарафыннан Дәвалау оешмасында булу кагыйдәләре бозылу, тору режимының һәм дәвалау планының башка бозылулары турында Учреждениегә мәгълүмат җиткерергә.

2.6. Дәвалау оешмасы, эпидемиологик хәлне исәпкә алып, Дәвалау оешмасының локаль норматив актларына туры китереп, стационар шартларда аңа дәвалау ярдәме күрсәткәндә, тәрбияләнүче белән Озата йөрүченең Дәвалау оешмасында бергә булуын контрольдә тотарга бурычлы.

## III. Дәвалау оешмасында тәрбияләнүчене карап тотуны матди тәэмин итү

3.1. Стационар шартларда дәвалау ярдәме күрсәтелгәндә Учреждение Озата йөрүче белән Дәвалау оешмасында булган тәрбияләнүчене Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы

законнары нигезендә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мзхрүм калган балалар өчен билгеләнгән нормаларга туры китереп, кием-салым һәм аяк киеме белән тәэмин итә.

3.2. Стационар шартларда аңа дәвалау ярдәме күрсәткәндә тәрбияләнүчене Дәвалау оешмасында Озата йөрүче тарафыннан озатып йөрү түләүсез нигездә гамәлгә ашырыла.

## IV. Шартнамәнең гамәлдә булу чоры

4.1. Шартнамә имзаланган көннән үз көченә керә.

4.2. Шартнамәнең гамәлдә булу вакыты: 20___ елның «____» ___________ башлап 20___ елның «____» __________ кадәр (әгәр дә госпитализацияләү чоры билгеләнгән булса) яки тәрбияләнүче Дәвалау оешмасының стационар бүлекчәсеннән чыгарылганчыга кадәр.

Шартнамә вакытыннан алда өзелергә мөмкин, түбәндәге очракларда:

Озата йөрүче үз бурычларын үтәмәгән яки тиешле дәрәҗәдә башкармаган очракта;

Озата йөрүче авырып киткәндә;

тәрбияләнүчене Дәвалау оешмасында озата йөрүне дәвам иттерү өчен комачаулый торган башка шартлар барлыкка килгәндә.

## V. Өстәмә шартлар

5.1. Әлеге Шартнамәне үтәү барышында барлыкка килгән барлык бәхәсләр һәм каршылыклар сөйләшүләр алып бару юлы белән хәл ителәчәк. Җайга салынмаган бәхәсле мөнәсәбәтләр законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

5.2. Шартнамәгә кертелгән барлык үзгәрешләр, өстәмәләр язма рәвештә рәсмиләштерелсә һәм өч як тарафыннан имзаланса, гамәлдә була.

5.3. Әлеге Шартнамә якларның һәркайсы өчен бер үк юридик көчкә ия булган 3 нөсхәдә төзелде.

## V1. Якларның реквизитлары

<table>
<tr><th>Учреждение</th><th>Дәвалау оешмасы</th><th>Озата йөрүче</th></tr>
<tr><td>______________________________<br>______________________________<br>_________________<br>(учреждение исеме)</td><td>_________________________<br>_________________________<br>_________________________<br>_<br>(учреждение исеме)</td><td>________________________________<br>______________<br>(коммерциясез оешма исеме)<br>______________________________<br>______________________________<br>(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))</td></tr>
<tr><td>Юридик адрес:<br>_______________________<br>______________________________<br>______________<br>Тел.:<br>___________________________</td><td>Юридик адрес:<br>_______________________<br>_________________________<br>__________________<br>Тел.:<br>_________________________</td><td>Теркәлү адресы:<br>_______________________<br>________________________________<br>______________<br>Яшәү адресы:<br>_______________________<br>_______________________<br>(волонтерлар (ирекле ярдәмчеләр) өчен)<br>Тел.:___________________</td></tr>
<tr><td>Банк реквизитлары:<br>Салым түләүченең тәңгәллек номеры:<br>Исәпкә алу сәбәбе коды:<br>И-х/с<br>Ш / с<br>МБ бүлекчәсе<br>Татарстан Республикасы<br>Банкның тәңгәллек коды</td><td>Банк реквизитлары:<br>Салым түләүченең тәңгәллек номеры:<br>Исәпкә алу сәбәбе коды:<br>И-х/с<br>Ш / с<br>МБ бүлекчәсе<br>Татарстан Республикасы<br>Банкның тәңгәллек коды</td><td>Юридик адрес:<br>______________________<br>________________________________<br>__________<br>(коммерциясез оешмалар өчен)<br>Тел.:__________________________<br>__________</td></tr>
</table>

| | | |
|---|---|---|
| Имза:<br>______________________________/<br>_____________________<br>Мөһер урыны | Имза:<br>______________________________/<br>_____________________<br>Мөһер урыны | Имза:<br>______________________________/<br>_____________________ |